КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 29 март г.Казань № 184

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарны Россиянең һәм чит илләрнең белем бирү һәм фәнни оешмаларында әзерләүгә һәм аларның стажировкасына Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең «Алгарыш» гранты турында» 2010 ел, 21 май, 398 нче карары белән расланган Гражданнарны Россиянең һәм чит илләрнең белем бирү һәм фәнни оешмаларында әзерләүгә һәм аларның стажировкасына Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең «Алгарыш» грантын бирү буенча республика комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарны Россиянең һәм чит илләрнең белем бирү һәм фәнни оешмаларында әзерләүгә һәм аларның стажировкасына Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең «Алгарыш» гранты турында» 2010 ел, 21 май, 398 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 23 февраль, 157 нче; 2013 ел, 11 май, 319 нчы; 2013 ел, 31 май, 371 нче; 2014 ел, 25 сентябрь, 673 нче; 2014 ел, 24 декабрь, 1019 нчы; 2015 ел, 3 июнь, 400 нче; 2016 ел, 28 октябрь, 795 нче; 2016 ел, 28 декабрь, 1019 нчы; 2017 ел, 14 июнь, 387 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданнарны Россиянең һәм чит илләрнең белем бирү һәм фәнни оешмаларында әзерләүгә һәм аларның стажировкасына Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең «Алгарыш» грантын бирү буенча республика комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Яшь галимнәр», «Ике диплом» категорияләре буенча дәгъва итүчеләр арасыннан конкурс нигезендә сайлап алу буенча ярдәмче комиссиядә:

ярдәмче комиссия составыннан Э.Н.Фәттаховны, Г.С.Дьяконовны, А.Н.Новикованы чыгарырга;

ярдәмче комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министры, Республика комиссиясе рәисе урынбасары, ярдәмче комиссия рәисе Рафис Тимерхан улы Борһановны;

югары белем бирүче «Казан илкүләм тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры вазыйфаларын башкаручы Сергей Владимирович Юшконы (килешү буенча);

«Югары белем бирүче мәгариф оешмалары», «Укытучылар һәм фәнни хезмәткәрләр», «Яшь белгечләр» категорияләре буенча грант алуга дәгъва итүчеләрне конкурс нигезендә сайлап алу буенча ярдәмче комиссиядә:

ярдәмче комиссия составыннан Н.Г.Баһаутдинованы, Р.И.Замановны, В.Г.Ивановны чыгарырга;

ярдәмче комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

югары белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә караган Психология һәм мәгариф институты директорының фән һәм үсеш буенча урынбасары Тимирхан Булат улы Алишевне (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының югары, урта һөнәр белеме бирү һәм фән бүлеге башлыгы урынбасары Андрей Андреевич Выборновны;

югары белем бирүче «Казан илкүләм тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең – Татарстан Республикасы җитәкчеләрен һәм белгечләрен яңадан әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү тармакара төбәк үзәгенең уку-укыту эшләре буенча проректоры Алексей Васильевич Бурмистровны (килешү буенча);

«Белем бирү оешмалары хезмәткәрләре» категориясе буенча грант алуга дәгъва итүчеләрне конкурс нигезендә сайлап алу буенча ярдәмче комиссиядә:

ярдәмче комиссия составыннан И.Р.Мөхәммәтовны, И.А.Сахнованы чыгарырга;

ярдәмче комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

«Белем бирү сыйфатын мониторинглау республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры Айрат Ринат улы Мөхәммәтовны;

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының мәгариф идарәсе башлыгы Илнар Рүзәл улы Һидиятовны (килешү буенча);

Илсур Гәрәй улы Һадиуллин вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары, Республика комиссиясе рәисе урынбасары, ярдәмче комиссия рәисе»;

«Проект төркемнәре» категориясе буенча грант алуга дәгъва итүчеләрне конкурс нигезендә сайлап алу буенча ярдәмче комиссиядә:

Равил Рәид улы Сиражиев вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү һәм аларга ярдәм күрсәтү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе»;

«WorldSkills» категориясе буенча грант алуга дәгъва итүчеләрне конкурс нигезендә сайлап алу буенча ярдәмче комиссиядә:

ярдәмче комиссия составыннан А.В.Сидоренконы чыгарырга;

ярдәмче комиссия составына «Һөнәри компетенцияләрне үстерү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы генераль директоры Эмиль Фидаил улы Гобәйдуллинны (килешү буенча) кертергә;

Алмаз Кави улы Кадыйров вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Н.В.Лемаев исемендәге Нефть химиясе һәм нефть эшкәртү көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин